ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

13 март 2026ел

№ 2455

Яр Чаллы шәһәренең «5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмә, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитет карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Яр Чаллы шәһәренең «5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2021 елның 12 июлендәге 4692 номерлы;

2) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2021 елның 12 июлендәге 4692 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 9 августындагы 4010 номерлы;

3) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2021 елның 12 июлендәге 4692 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 28 мартындагы 2335 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 13 мартындагы
2455 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәя |
|---|---|---|---|
| I. Белем бирү һәм үстерү хезмәтләре | | | |
| 1 | Модельләштерүдә уйлап табу мәсьәләләрен чишү теориясе (ТРИЗ) | кеше/ай | 2500,00 |
| 2 | Конструкцияләүдә ТРИЗ | кеше/ай | 2500,00 |
| 3 | Инженерлык графикасында ТРИЗ | кеше/ай | 2500,00 |
| 4 | Практик электроникада ТРИЗ | кеше/ай | 2500,00 |
| 5 | 3D модельләштерүдә һәм прототиплаштыруда ТРИЗ | кеше/ай | 2500,00 |
| 6 | Проект эшчәнлегендә ТРИЗ | кеше/ай | 2000,00 |
| 7 | Башлангыч робот техникасында ТРИЗ | кеше/ай | 2500,00 |
| 8 | Башлангыч техник модельләштерүдә ТРИЗ | кеше/ай | 500,00 |
| 9 | «Самоделкин» мастер-класслары үткәрү | кеше/сәгать | 100,00 |
| 10 | «Яндырып бизәк төшерү» мастер-класслары үткәрү | кеше/сәгать | 300,00 |
| 11 | «3D дөньясында» мастер-класслары үткәрү | кеше/сәгать | 300,00 |
| 12 | «Дага» мастер-класслары үткәрү | кеше/сәгать | 200,00 |
| 13 | Программалаштыру мәктәбе (Python, Scratch) | кеше/ай | 2000,00 |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.А. Шәфыйкова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ